Азат Алмакаевны мин бала чагыннан ук белəм; кvрше малае иде.
Авылда фермерлык эше «Начинающий фермер» федераль программасын кабул иткəч активлашты. Ел саен авыл хужалыгы олкəсенə 15-10 яшь фермер vз эшен башлап жибəрə. Шулай, vткəн ел Татар Тавласы авылында яшəvче Азат Рəстəм улы Алмакаев та, югары белем алуына карамастан, авыл хужалыгы олкəсендə тугърълыклы булып кала: vз эшен ача.
Альбина белəн Азат мəктəптə бар предметтан да яхшы олгерə иделəр. Азатлар Аксен авылыннан Татар Тавласына кvчкəч, Наиль энесе туды. Əнилəре Луиза Аллям кызы, хезмəтне яратып vскəн һəм балаларына да хезмəткə хормəт тəрбиялəгəн. «Азатым – кул эшлəре остасы: ташчы да, плотник та, техника белəн дə дус. Мал-туар абзарын vз куллары белəн эшлəде, мунча да салды. Ə хəзер фермерлык эшенə чумды. Ана бу эш таныш. Балачактан ук мал-туар арасында кайнашты, ярдəм итə иде, - ди Луиза ханым. Авылыбызда элек котv-котv мал-туар асрый идек; жəй коне һəрбер йорт алдында котvне каршы алырга халык чыга иде һəм колхознын да берничə котvе бар иде. Ə хəзер бу авыр хезмəттəн кvп кеше ераклашты. Максатчан кешелəр генə мал-туар асрый бvген».
Азат, жəйге каникулларда колхозда комбайнер булып та эшлəгəн. Озын буе, кин жилкəсе дə мона ярдəм иткəн. Урта мəктəпне тəмамлап, вузда менеджер-житəкче белгечлеген алырга-ала, əмма һəрвакыт vз эшен оештырып ачарга телəде ул. «Совхоз юкка чыгу бик тə зур зыян китерде авылдашларыма, - ди Азат. - Авыл халкынын эше бар иде. Бvген ир-атларыбызнын кvбесе, гаилəлəреннəн аерылып, чит жирлəргə кəсеб эзлəп чыгып китəлəр; Таймырга кадəр житəлəр. Аларсыз Тавлабыз да буш. Əле ярый шəһəргə якын урнашканбыз, кайберəvлəр шунда йореп эшли. Ə мин - кече Ватаным патриоты – авылда яшим һəм килəчəгем унышы да биредə дип уйлыйм», - ди Азат Рəстəм улы Алмакаев.
Азат, тормыш иптəше Зульфия ярдəме белəн, «Яшь фермер» («Поддержка начинающих фермеров в РМ до 2020 года») программасы кысаларында сот житештерv буенча хужалык оештырган. Нəкъ шул программа авылда ныгып калырга ярдəм итə дə инде. Сотле сыерларны йоз башка кадəр житкерергə дигəн хыял белəн яши ул. Крестьян-фермерчылык статусына житəр очен аннан артыграк хайван булса да яхшы. Əмма мона ирешv кvп коч сорый. Белгəнебезчə, бvген сотлебикəлəрнен һəрберсе 70-80 мен сум тора. Хокvмəт ярдəмесез биредə берничек vсеш булдырып булмый. Мал-туар санын арттыру, яшəv урыннарын булдыру, ашамлыклар белəн тəэмин итv – шул инде Азатнын vз

эше перспективасы. Ә бvген башлап жибәргән эшендә барлыгы ике сыеры, бозавы һәм оч баш иткә vстерә торган vгезе бар. Әлегә Азатнын 20 баш сыерлык абзары бар, тагы ун сыерлык абзары тозелеп бетәргә жыена. Әкренләп алга атлый ул, планнарын тормышка ашыра. Крестьян-фермер статусына кадәр vсәчәгенә омет бар, һәрхәлдә хокvмәтнен ярдәме белән.
- Бvген малларга азык алырга була, акчан гына булсын,- ди яшь фермер, - ә малларны грант акчасына алырга исәп. Абзарлар белән булган сорауны да чишәргә уебызда – колхознын элекке коровнигын ремонтлап әзерләргә жыенам. Плаштырылганча килеп чыкса, нәтижә булыр дип ышанам.
Азат Алмакаев сот эшкәртv белән шогыльләнә, чонки бvген экологик чиста каймак, эремчек, ак майны халык яратып, «эх!» дигәнче алып бетерә. Саулык кыйбатрак бит. Тагы алар бәяләрне дә арттырмыйлар.
- Безнен сот ашамлыкларыбыз кибетнекенә караганда очсыз, - ди Луиза Аллям кызы, - бәя белән сыйфат сатып алу момкинчелеген билгели, ә безнен бу олкәдә проблема юк. Азатым сотне эшкәртv мини-заводы сатып алырга хыяллана. Ансыз кыенга туры киләчәк. Тагы сыерларнын нәсел-лесен, тикшерелгән сатучыдан, коненә 35 литр бирә торган элит токымлысын ала. Фермер булып vсv очен озак юл vтәсе бар. Башта егерме баш сыер белән башлап жибәрергә уйлый улым, аннары әкренләп сыер котvен vстерер. Шуна токымлы сыерларнын бозауларын сыерга vстерергә планлаштыра. Ә vгез бозаулары иткә китәчәк. Технологияләре дә билгеле, сату юллары шомарган. Малны бугазлау цехыннан итне перекупщиклар сатып ала. Авылыбыз халкы да итне дә, сот ашамлыкларын да яратып ала. Шулай инде авыл хужалыгындагы ит-сот производствасы бара.
Азат Рәстәм улы эш урыннары булдыру турында да кайгырткан. Алтылап кеше кирәк булачак. Ин элек әнисе Луиза Аллям кызы белән vги әтисе Малик Әхмәт улы, энесе Наиль һәм сенеле Альбина, әнисенен апасы Равилә Исхак кызы һәм Азат vзе эшләр. Малик Әхмәт улынын малны бугазлау цехы Азатка зур ярдәм булачак. Ул райондагы цехлар арасында уйланылган һәм топле булуы белән аерылып тора. Цех электр, су белән тәэмин ителә, канализациясе эшли, алты хайван тvшенә суыткыч бар, ветеринар очен бvлмә дә булдырылган. Тvшне элеп кую жиһазлары, эшкәртv һәм машинага тияv линияләре механизацияләнгән һәм барлык санитар таләпләргә жавап кайтара. Бvген биредә беръюлы дvрт мал бугазлана. Авыл хужалыгы министрлыгы белгечләре бу бугазлау цехын республикабызда ин яхшыларнын берсе дип бәяли. Фермер буларак башлаган Алмакаев Азатнын эше, Малик Әхмәт улынын малны бугазлау цехы белән бергә, унар дип уйларга урын бар. Шәхси тормышына килгәндә - Азат Ростәм улы белән Зульфия ханым ике балаларына да хезмәткә хормәт тәрбиялиләр. Киләчәктә эшләренен дәвамы булачак дип тә әйтәсе килә.

Наилә Насырова